КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 17 ноябрь г.Казань № 883

Мигрантларны социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән кереш (юнәлеш бирү) курсларын үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 18 декабрь, 1006 нчы карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасы чараларын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Мигрантларны социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән кереш (юнәлеш бирү) курсларын үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

30 көн эчендә мигрантларны социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән кереш (юнәлеш бирү) курсларын үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларның Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алу хокукына конкурста катнашуга гаризаларын карап тикшерү буенча конкурс комиссиясе составын расларга;

бу карар белән расланган Тәртипне куллану мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыручы социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 28 март, 193 нче;

«Хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән проектларны тормышка ашыручы социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 28 март, 193 нче карары белән расланган Хезмәт мигрантларын социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән проект-ларны тормышка ашыручы социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 ел, 8 апрель, 199 нчы.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 17 ноябрь, 883 нче
карары белән расланды

# Мигрантларны социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән кереш (юнәлеш бирү) курсларын үткәрү чараларын тормышка ашыру өчен социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

## I. Субсидияләр бирү турында гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм, юридик затларның мигрантларны социаль адаптацияләү һәм интеграцияләү, эшкә урнаштыру мәсьәләләрен хәл итүгә багышланган социаль әһәмиятле эшчәнлегенә дәүләт ярдәме күрсәтү кысаларында кереш (юнәлеш бирү) курсларын үткәрү эшчәнлеген гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында, теркәлгән һәм эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыра торган социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмаларга (алга таба – коммерциягә карамаган оешмалар) конкурс нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидия) бирү механизмын билгели.

1.2. Бу Тәртиптә түбәндәге төп төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

мигрант – законнар белән билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясенә килгән чит ил гражданы яки гражданлыгы булмаган зат;

мигрантларны социаль адаптацияләүгә һәм интеграцияләүгә юнәлдерелгән кереш (юнәлеш бирү) курслары (алга таба – кереш (юнәлеш бирү) курслары) – мигрантлар өчен түбәндәге мәҗбүри сораулар исемлеге буенча мәгълүматның база җыелмасын бирү юлы белән мигрантларга гигиена тәрбиясе бирү һәм аларның социаль-тискәре үз тотышын профилактикалау буенча планлы рәвештә эш алып баруны күздә тота торган курслар:

Россия Федерациясе территориясендә мигрантларның төп хокуклары һәм бурычлары;

хокукка каршы һәм экстремизмга бәйле үз тотышны профилактикалау;

җәмгыятьтә үз-үзеңне тоту нормалары һәм культурасы, шәһәрдә үз-үзеңне тотуның иң мөһим нормалары һәм шәһәрдә булу кагыйдәләре;

йогышлы һәм социаль әһәмиятле авыруларны, наркоманияне һәм алкоголизмны профилактикалау, шәхси гигиена;

беренче ярдәм күрсәтү нигезләре;

мигрантларга юнәлдерелгән хезмәт базары турында мәгълүмат;

Татарстан Республикасының традициядәге диннәре турында мәгълүмат;

Россия тарихының төп вакыйгалары һәм Россия Федерациясенең төп законнары турында мәгълүмат;

рус сөйләм теле нигезләре;

ярдәм күрсәтү хезмәтләре, дәүләт хезмәтләре системасы турында мәгълүмат.

1.3. Субсидияләр бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – вәкаләтле орган) тора.

Субсидияләр коммерциягә карамаган оешмаларга бу Тәртипнең 1.1 нче пунктында күздә тотылган максатлар өчен тиешле финанс елына вәкаләтле органга билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары һәм бюджет ассигнованиеләре чикләрендә бирелә.

1.4. Субсидияләр коммерциягә карамаган оешмаларга коммерциягә карамаган оешмаларның субсидия алу хокукына кереш (юнәлеш бирү) курслары үткәрү эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча проектларын (алга таба – проект) конкурс нигезендә сайлап алу (алга таба – конкурс) йомгаклары буенча бирелә.

1.5. Конкурс оештыру һәм үткәрү эше түбәндәге принципларга нигезләнә:

гавами һәм ачык булу;

коммерциягә карамаган оешмаларның конкурста катнашуга хокуклары тигез булу;

экспертлар фикерләрен исәпкә алу;

ярышу, гаризаларны карап тикшерү конкурс нигезендә булу.

1.6. Проектта түбәндәге чаралар каралырга тиеш:

мигрантларның максатчан аудиториясен билгеләү, контингентны туплау һәм мигрантларны кереш (юнәлеш бирү) курсларында катнашырга җибәрү;

кереш (юнәлеш бирү) курсларын оештыру һәм үткәрү;

кереш (юнәлеш бирү) курсларын үткәрү барышында мигрантлар өчен рус, үзбәк һәм таҗик телләрендә титрлары булган визуаль ярдәмлекләр куллану;

мигрантларга бу Тәртипнең 1.2 пунктындагы дүртенче – унөченче абзацларында бәян ителгән кереш (юнәлеш бирү) курслары сорауларының мәҗбүри исемлеге буенча кыскача мәгълүмат белән буклетлар һәм брошюралар рәвешендә тарату өчен билгеләнгән рус, үзбәк һәм таҗик телләрендә басма материаллар бирү;

мигрантларның кереш (юнәлеш бирү) курсларында катнашканга кадәр һәм катнашканнан соң мәгълүматка ия булу дәрәҗәсен кереш (юнәлеш бирү) курсларында катнашучыларның барысыннан әлеге сораулар исемлеге буенча анкета алып бәяләү;

проектны тормышка ашыру барышын массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту;

Татарстан Республикасының иҗтимагый оешмалары, мәгариф оешмалары, эш бирүчеләре, кызыксынучы башкарма хакимият органнары вәкилләре катнашында проектны тормышка ашыру йомгаклары буенча утырышлар үткәрү;

проект кысаларында тормышка ашыру өчен коммерциягә карамаган оешма тарафыннан мөстәкыйль тәкъдим ителгән, бу Тәртипнең 1.1 нче пунктында бәян ителгән максатларга туры килә торган башка чаралар.

Проект аның түбәндәге нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен һәм аларның күздә тотыла торган мәгънәләрен үз эченә алырга тиеш:

кереш (юнәлеш бирү) курсларында катнашкан мигрантлар санын;

кереш (юнәлеш бирү) курсларында катнашкан мигрантларның гомуми санында әлеге курсларда катнашканнан соң кереш (юнәлеш бирү) курслары сораулары исемлеге буенча анкетаның барлык тикшерү сорауларына дөрес җавап биргән мигрантлар өлеше.

Проект вәкаләтле орган белән конкурста җиңүче арасында субсидия бирү турында килешү төзегән көннән алып 12 айдан да артмаган вакыт эчендә тормышка ашырылырга тиеш.

1.7. Конкурста законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә үзләренең гамәлгә кую документлары нигезендә конкурс игълан иткән көнгә кадәр кимендә бер ел гамәлгә ашыра торган коммерциягә карамаган оешмаларга катнашырга рөхсәт ителә.

Субсидия коммерциягә карамаган оешмаларга субсидия бирү турында килешү төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан килә торган айның беренче көненә алар түбәндәге шартларга туры килгән очракта бирелә:

үзгәртеп оештыру, ябу, банкротлык процессында тормаган;

чит ил юридик затлары, шулай ук Россия юридик затлары (аларның устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы белән раслана торган Салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм финанс операцияләрен үткәргәндә мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмый торган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория аның теркәлү урыны булган чит ил юридик затларның катнашу өлеше барысы бергә 50 проценттан артыграк булган) булмаган;

аларның устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый оешмалар катнашында сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, хуҗалык ширкәтләре һәм җәмгыятьләре, шулай ук аларның устав (җыелма) капиталларында шундый ширкәтләр һәм җәмгыятьләр катнашында коммерция оешмалары булмаган;

бу Тәртипнең 1.1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокук актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучылар булмаган;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча түләнмәгән бурычлары булмаган

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка норматив актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган;

бу Тәртип нигезендә элегрәк бирелгән бюджет акчасын (субсидияләрне) максатчан һәм (яки) нәтиҗәле файдаланмауны булдырмаган.

1.8. Вәкаләтле орган бу Тәртип кысаларында түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

конкурс үткәрү турында карар кабул итә;

конкурс үткәрүне оештыра;

конкурста катнашуга гариза (алга таба – гариза) һәм проект формасын, гаризаларны карап тикшерү буенча конкурс комиссиясенең шәхси составын (алга таба – конкурс комиссиясе), бирелә торган субсидияләр күләмен күрсәтеп, конкурста җиңүчеләр исемлеген раслый;

конкурс, конкурста катнашучыларга карата таләпләр һәм аның йомгаклары турындагы мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны тәэмин итә;

гаризаларны әзерләү мәсьәләләре буенча консультация бирүне оештыра;

гаризаларны һәм аларга теркәлгән документларны кабул итүне һәм теркәүне оештыра;

бирелгән гаризаларның саклануын тәэмин итә;

конкурс комиссиясе эшчәнлеген оештыру-техник яктан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

конкурста җиңүчеләргә субсидияләр бирү турында карар кабул итә;

конкурста җиңүчеләр белән субсидияләр бирү турында килешүләр төзи, шуның белән бергә килешүләрдә субсидияләр бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләрен, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү турында һәм субсидиядән файдалану турында хисаплылык бирү вакытларын һәм формаларын билгели;

бирелгән субсидияләрдән максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыра.

Вәкаләтле орган конкурс үткәрү турында карар кабул иткән көннән бу Тәртипнең 2.6 нчы пункты белән күздә тотылган гаризаларны тикшерү вакыты тәмамланган көннән соң килә торган көнгә кадәрге чорда конкурс үткәрмәү турында карар кабул итәргә хокуклы.

1.9. Конкурс комиссиясе түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

гаризаларга эксперт бәяләмәсе бирүне үткәрү өчен җәлеп ителә торган экспертлар исемлеген төзи һәм раслый;

гаризаларның бу Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

конкурста катнашырга рөхсәт ителгән коммерциягә карамаган оешмалар исемлеген һәм конкурста катнашырга рөхсәт ителмәгән коммерциягә карамаган оешмалар исемлеген раслый;

гаризаларның эксперт бәяләмәсе нәтиҗәләрен карап тикшерә һәм, кирәк булганда, тапшырылган гаризалар буенча барлыкка килә торган мәсьәләләрне ачыклау максаты белән утырышларга коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләрен чакыра;

номиналь коэффициент күләме турында карар чыгара;

гариза рейтингының иң чик мәгънәсен булдыра, шуның белән аны тапшырган конкурста катнашучы җиңүче дип танала;

конкурста җиңүчеләр исемлеген билгели.

1.10. Конкурс комиссиясе үз утырышын әгъзаларының кимендә өчтән икесе булганда үткәрә. Конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә һәм, аның өчен конкурс комиссиясендә катнашучы әгъзалар 50 проценттан артыграк тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала. Тавышлар тигез булган очракта, рәис итүченең тавышы хәлиткеч тавышка ия була.

1.11. Конкурс комиссиясе карарлары конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аның утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары имза куя һәм конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан конкурс комиссиясе утырышы үткәрелгән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган биш көн эчендә раслана. Конкурс комиссиясе әгъзаларының үз фикере булса, бу фикерләр шулай ук конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә теркәлә.

Конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе, расланган көннән өч көннән дә соңга калмыйча, вәкаләтле органның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

1.12. Конкурс комиссиясе әгъзасы конкурс йомгаклары белән шәхсән (турыдан-туры яки читләтеп) кызыксынган яки конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясарга сәләтле башка хәлләр булган очракта, ул бу турыда конкурс комиссиясенә гаризаларны карап тикшерә башлаганга кадәр язмача хәбәр итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе әгъзасының шәхсән кызыксынуы дип аның конкурс комиссиясе әгъзасы, аның якын туганнары – ире, хатыны, ата-анасы, балалары, уллыкка алучылар, уллыкка алынганнар, бертуган абыйлары-энеләре һәм бертуган апалары-сеңелләре, бабалары, әбиләре, оныклары, шулай ук конкурс комиссиясе әгъзасы белән финанс йөкләмәләре яки башка йөкләмәләр бәйләп торган гражданнар яки оешмалар өчен акчалата йә натуралата түләнә торган формада керемнәр, турыдан-туры матди файда рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеген аңларга кирәк.

Конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясарга мөмкин булган сәбәпләргә түбәндәгеләр керә:

конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының, гамәлгә куючы, күмәк орган әгъзасы, бер үзе хуҗа булган башкарма орган яки хезмәткәр буларак, конкурста катнашучы булып торучы коммерциягә карамаган оешма эшчәнлегендә (шул исәптән соңгы 12 ай дәвамында) катнашуы;

конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының конкурста катнашучы булып торучы оешманың гамәлгә куючысы, конкурста катнашучысы, әгъзасы булып торучы коммерциягә карамаган оешма эшчәнлегендә гамәлгә куючы, яки бер үзе хуҗа булган башкарма орган сыйфатында (шул исәптән соңгы 12 ай дәвамында) катнашуы;

конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының конкурста катнашучы булып торучы коммерциягә карамаган оешма белән шартнамәле мөнәсәбәтләрдә (шул исәптән соңгы 5 ел дәвамында) булуы;

конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының конкурста катнашучы булып торучы коммерциягә карамаган оешмадан акча, башка мөлкәт,

матди файда (шул исәптән түләүсез башкарылган эшләр, күрсәтелгән хезмәтләр рәвешендә) (шул исәптән соңгы 5 ел дәвамында) алуы;

конкурс комиссиясе әгъзасының яки аның якын туганнарының конкурста катнашучы булып торучы коммерциягә карамаган оешма, аның гамәлгә куючысы, җитәкчесе, хезмәткәре белән суд бәхәсләре (шул исәптән соңгы 5 ел дәвамында) булуы;

конкурс комиссиясе әгъзасының конкурста катнашучы булып торучы коммерциягә карамаган оешма эшендә ихтыярый зат сыйфатында (шул исәптән соңгы 12 ай дәвамында) катнашуы;

конкурс комиссиясе әгъзасының шәхси кызыксынуы белән конкурс комиссиясе функцияләре арасында каршылыклар килеп чыга яки килеп чыгарга мөмкин булган башка хәлләр.

Конкурс комиссиясе, аңа конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясарга мөмкин булган сәбәпләр турында мәгълүмат кергән очракта, әлеге мәгълүмат алынган көннән 10 көн эчендә аларны карап тикшерергә һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итәргә тиеш:

конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуын туктатып торырга;

конкурс комиссиясе әгъзасының шәхсән кызыксынуы яки конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясарга сәләтле башка хәлләр булган гаризаларны конкурс комиссиясе әгъзасы конкурс комиссиясе утырышында булмаганда яки конкурс комиссиясе әгъзасын әлеге гаризалар турында фикер алышуда катнаштырмыйча карап тикшерергә;

конкурс йомгакларында конкурс комиссиясе әгъзасының шәхсән кызыксынуы булмау турында игълан итәргә.

Конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс йомгаклары белән шәхсән кызыксынуы яки конкурс комиссиясе әгъзасының конкурс комиссиясе эшендә катнашуына йогынты ясарга сәләтле башка хәлләр булу турындагы мәгълүмат, шулай ук конкурс комиссиясенең мондый мәгълүматны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карарлары конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә күрсәтелә.

## II. Гаризаларны бирү шартлары һәм тәртибе

2.1. Конкурс үткәрү турындагы игълан вәкаләтле орган тарафыннан конкурс үткәрү турында карар кабул ителгән көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган биш көн эчендә һәм гаризаларны кабул итә башлаган көнгә кадәр кимендә биш календарь көн кала вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла. Игъланда конкурс үткәрү вакыты, урыны, предметы һәм тәртибе, гаризаларны кабул итә башлау һәм аның тәмамлану вакытлары турында мәгълүматлар булырга тиеш.

Гаризаларны кабул итү гаризаларны кабул итә башлаган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 20 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

2.2. Конкурста катнашу өчен коммерциягә карамаган оешма вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча вәкаләтле органга, түбәндәгеләрне теркәп, гариза кертә:

вәкаләтле орган тарафыннан расланган форма буенча тормышка ашыру вакыты 12 айдан да артыграк булмаган проектны;

коммерциягә карамаган оешма уставы күчермәсен, әгәр дә күчермә нотариуста расланмаган булса, төп нөсхәсен күрсәтеп;

Федераль салым хезмәтенең «Салым түләүченең (җыем түләүче, иминият кертемнәре түләүче, салым агентының) салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмәләрен үтәү турындагы белешмә кәгазе формасын, аны тутыру тәртибен һәм аны электрон рәвештә бирү форматын раслау хакында» 2017 елның 20 гыйнварындагы ММВ-7-8/20 номерлы боерыгы белән билгеләнгән форма буенча конкурста катнашуга гариза бирү көне алдыннан кимендә бер ай алдан килә торган көнгә карата белешмә кәгазен;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокук актлары нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау турында җитәкче һәм баш бухгалтер кул куйган, коммерциягә карамаган оешманың мөһере (мөһер булганда) белән беркетелгән белешмә кәгазен (ирекле рәвештә);

коммерциягә карамаган оешманың бу Тәртипнең 1.1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокук актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган, җитәкче һәм баш бухгалтер кул куйган, коммерциягә карамаган оешманың мөһере (мөһер булганда) белән беркетелгән белешмә кәгазен;

коммерциягә карамаган оешманың үзгәртеп оештыру, ябу, банкротлык процессында тормавын һәм аңа карата Россия Федерациясенең бурычларны түләргә хәл җитмәү (банкротлык) турындагы законнары нигезендә бурычларны түләргә хәл җитмәү (банкротлык) турында эш ачылмауны раслый торган, җитәкче кул куйган белешмә кәгазен;

салым органнында исәпкә куелу турында таныклык күчермәсен;

юридик затка карата үткәрелә торган ябу, эшчәнлекне туктату яки банкротлык процедуралары булмау турында белешмә кәгазен;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында язылган бит күчермәсен;

юридик зат җитәкчесе тарафыннан расланган юридик затның түбәндәгеләр булуын раслый торган документлар күчермәләрен:

мигрантларга мәгълүмати, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү, йогышлы авыруларны һәм социаль-тискәре үз тотышны профилактикалау эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәҗрибәсе;

мигрантларга мәгълүмати, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү, йогышлы авыруларны һәм социаль-тискәре үз тотышны профилактикалау эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Татарстан Республикасының дәүләт башкарма хакимият органнары һәм оешмалары һәм (яки) федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары белән хезмәттәшлек итү тәҗрибәсе;

проектны тормышка ашыру өчен кирәкле матди-техник база;

проектны тормышка ашыруны медицина, социаль эш, мәгариф, психология өлкәсендә юнәлешле белеме, мигрантларга мәгълүмати, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү, йогышлы авыруларны һәм социаль-тискәре үз тотышны профилактикалау буенча эш тәҗрибәсе булган квалификацияле белгечләр белән тәэмин итү;

мигрантларга мәгълүмати, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү, йогышлы авыруларны һәм социаль-тискәре үз тотышны профилактикалау эшчәнлегенә багышлап эшләнгән һәм рецензияләнә торган фәнни журналларда басылып чыккан мәгълүмати һәм методик материаллар, фәнни басмалар;

гигиена тәрбиясе бирү өлешендә медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга хокук бирә торган лицензияләр.

Юридик зат бу пунктның дүртенче, сигезенче – унынчы абзацларында санап үтелгәннәр арасыннан документларны тапшырмаган очракта, вәкаләтле орган әлеге документларны ведомствоара хезмәттәшлек итү тәртибендә соратып ала.

Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан бу пунктның уникенче – унҗиденче абзацларында күрсәтелгән документлар тапшырылмау конкурс комиссиясе тарафыннан юридик затның гаризасына конкурста катнашырга рөхсәт ителми дип тануга китерми.

2.3. Коммерциягә карамаган оешма гаризаларны кабул иткән чорда үз гаризасын кире алырга, шулай ук элегрәк кире алынган гаризасын, кирәк булганда, үз теләге белән үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертеп, яңадан кертергә хокуклы.

2.4. Коммерциягә карамаган оешма бер генә гариза бирергә мөмкин, аның составында конкурста катнашу өчен бер генә проект тәкъдим ителә.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар тегелгән, нумерланган һәм коммерциягә карамаган оешманың мөһере (мөһере булганда) һәм вәкаләтле затның имзасы белән расланган булырга тиеш. Барлык документларда басма хәрефләр белән җыелган булырга тиеш.

Кырулар һәм төзәтүләр (мөһер (мөһер булганда) белән беркетелгән һәм коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле заты имзасы белән таныкланган төзәтүләрдән тыш) рөхсәт ителми.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар кәгазь һәм электрон чыганакларда (doc һәм pdf форматларында) турыдан-туры вәкаләтле органга кертелә яки аңа почта аша җибәрелә.

2.5. Гаризалар кабул итү чорында гаризалар кабул иткәндә вәкаләтле орган аны гаризаларны исәпкә алу журналында гариза кергән көндә теркәүгә ала һәм гариза бирүчегә, аны алган көнен һәм бирелгән теркәү номерын күрсәтеп, гариза алу турында раслама кәгазе бирә.

Гаризалар кабул итү чорында гариза вәкаләтле органга почта аша кергәндә, ул гариза кергән көннән бер эш көне эчендә гаризаларны исәпкә алу журналында теркәлә. Бу очракта гариза алу турында раслама кәгазе язылмый, гаризаларны исәпкә алу журналында теркәү көне итеп почта аша җибәрелә торган әйбердәге штемпель белән расланган почта аша җибәрелә торган әйберне элемтә оешмасына тапшыру көне күрсәтелә.

Гаризалар кабул итү вакыты башланганга кадәр яки гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң вәкаләтле органга (шул исәптән почта аша) кергән гариза теркәүгә алынмый һәм конкурста катнаша алмый, вәкаләтле орган бу турыда гариза җибәргән коммерциягә карамаган оешмага гариза кергән көннән биш эш көне эчендә гаризада күрсәтелгән адрес буенча хәбәр итә.

2.6. Конкурс комиссиясе теркәүгә алынган гаризаларны гаризалар кабул итү тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бу Тәртип белән билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә тикшерә.

2.7. Гариза конкурс комиссиясе тарафыннан, әгәр дә ул бу Тәртипнең таләпләренә туры килсә, ә гариза биргән коммерциягә карамаган оешма бу Тәртип белән аңа карата куела торган таләпләргә туры килсә, конкурста катнаша ала дип санала.

Конкурс комиссиясе түбәндәге очракта гаризадан баш тарту турында карар кабул итә:

гариза бу Тәртипнең таләпләренә туры килмәгән, шул исәптән вәкаләтле орган боерыгы белән расланган формага туры килмәгән һәм (яки) гаризага бу Тәртипнең 2.2 нче пунктындагы икенче – җиденче абзацларында санап үтелгәннәр арасыннан документлар теркәлмәгән;

гаризада дөрес булмаган мәгълүмат булган;

гариза биргән коммерциягә карамаган оешма бу Тәртип белән куела торган таләпләргә туры килмәгән.

Вәкаләтле орган конкурс комиссиясенең гаризадан баш тарту турында кабул ителгән карары турында гариза биргән коммерциягә карамаган оешмага гаризада күрсәтелгән адрес буенча мондый карар кабул ителгән көннән 10 эш көне эчендә хәбәр итә.

2.8. Вәкаләтле орган конкурста катнаша ала дип саналган гаризаларны һәм аларга теркәлгән документларны бу Тәртипнең 2.6 нчы пунктында каралган гаризаларны тикшерү вакыты тәмамланганнан соң конкурс комиссиясе тарафыннан расланган экспертлар исемлегенә кертелгән экспертларга карап тикшерүгә тапшыра.

Әгәр дә гаризаларның берсе дә конкурста катнаша алмый дип танылса, вәкаләтле орган гаризалар кабул итә башлаган көнгә кадәр кимендә биш календарь көн кала вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында гаризаларны кабул итә башлау һәм аның тәмамлану вакытлары турында мәгълүмат урнаштыруны гамәлгә ашыра һәм бу Тәртипнең 2.5 нче һәм 2.8 нче пунктлары белән күздә тотылган гамәлләрне башкара, конкурс комиссиясе бу Тәртипнең 2.6 нчы һәм 2.7 нче пунктлары белән күздә тотылган гамәлләрне башкара.

## III. Гаризаларны бәяләү һәм конкурста җиңүчеләрне билгеләү

3.1. Экспертлар конкурс комиссиясе тарафыннан гаризалар тикшерелеп беткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә гаризаларны һәм аларга теркәлгән документларны бу Тәртипнең 3.2 нче пункты белән билгеләнгән

критерийлар нигезендә бәяли һәм эксперт бәяләмәләрен конкурс комиссиясенә тапшыра.

Һәр гариза ике эксперт тарафыннан карап тикшерелә. Әгәр дә гаризаны карап тикшергән экспертлар бәяләмәсе 35 һәм аннан да күбрәк баллга аерылса, гариза конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә торган өченче эксперт тарафыннан карап тикшерелә.

3.2. Гаризаларны бәяләү экспертлар тарафыннан түбәндәге критерийлар буенча гамәлгә ашырыла:

| Т/с | Гаризаларны бәяләү критерийлары | Бәя (баллар) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. Проектның әһәмиятлелеген һәм актуальлеген бәяләү критерийлары | | |
| 1.1. | Проектның бу Тәртипнең 1.1 нче пунктында бәян ителгән кереш (юнәлеш бирү) курсларын үткәрү эшчәнлеген гамәлгә ашыру максатларына туры килү | Баллар саны кертелгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 1.2. | Проект чараларының бу Тәртипнең 1.6 нчы пунктында бәян ителгән чаралар исемлегенә туры килү | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 1.3. | Кереш (юнәлеш бирү) курсларын үткәрү эшчәнлеген гамәлгә ашыру кысаларында тормышка ашыру өчен юридик зат тарафыннан мөстәкыйль тәкъдим ителгән чаралар булу, проект нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү өчен аларның әһәмиятлелеге һәм нәтиҗәлелеге | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 1.4. | Проект чараларының логикалы, үзара бәйләнешле һәм эзлекле булуы | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 1.5. | Проект массакүләм мәгълүмат чараларында проектны тормышка ашыру барышын яктыртуны күздә тота | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 2. Икътисадый нәтиҗәлелекне бәяләү критерийлары | | |
| 2.1. | Проектны тормышка ашыру чыгымнары нигезле булу | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 3. Социаль нәтиҗәлелекне бәяләү критерийлары | | |
| 3.1. | Проектны тормышка ашыру нәтиҗәлелеге күрсәткечләре булу һәм аларның мәгънәләре | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 4. Һөнәри компетенцияне бәяләү критерийлары | | |
| 4.1. | Коммерциягә карамаган оешманың мигрантларга мәгълүмат бирү, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү, йогышлы авыруларны һәм социальтискәре үз тотышны профилактикалау эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча документлар белән расланган тәҗрибәсе булу | 1 елга кадәр – 0,<br>1 елдан 2 елга кадәр – 2,<br>3 – 4 ел – 4,<br>5 – 6 ел – 6,<br>6 елдан күбрәк – 10 |
| 4.2. | Коммерциягә карамаган оешманың мигрантларга мәгълүмат бирү, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү, йогышлы авыруларны һәм социальтискәре үз тотышны профилактикалау эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт башкарма хакимият органнары һәм оешмалары һәм (яки) федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары белән хезмәттәшлек итү буенча документлар белән расланган тәҗрибәсе булу | 1 елга кадәр – 0,<br>1 елдан 2 елга кадәр – 2,<br>3 – 4 ел – 4,<br>5 – 6 ел – 6,<br>6 елдан күбрәк – 10 |
| 4.3. | Коммерциягә карамаган оешманың проектны тормышка ашыру өчен кирәкле матди-техник базасы булу | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| 4.4. | Проектны тормышка ашыруны медицина, социаль хезмәт, мәгариф, психология өлкәсендә юнәлешле белеме, мигрантларга мәгълүмат бирү, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү, йогышлы авыруларны һәм социаль-тискәре үз тотышны профилактикалау буенча эш тәҗрибәсе булган квалификацияле белгечләр белән тәэмин итү | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 4.5. | Коммерциягә карамаган оешманың мигрантларга мәгълүмат бирү, социаль һәм башка хезмәтләр күрсәтү, йогышлы авыруларны һәм социаль-тискәре үз тотышны профилактикалау эшчәнлегенә багышлап эшләнгән һәм рецензияләнә торган фәнни журналларда басылып чыккан мәгълүмати һәм методик материаллары, фәнни басмалары булу | Баллар саны тәкъдим ителгән проектны, гаризаның башка документларын бәяләү нәтиҗәләре буенча экспертлар тарафыннан билгеләнә – 0 баллдан 10 баллга кадәр |
| 4.6. | Коммерциягә карамаган оешманың гигиена тәрбиясе бирү өлешендә медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга хокук бирә торган лицензияләре булу | Лицензияләр булмау – 0 балл;<br>өлкәннәргә өстәмә белем бирү буенча мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия булу – 5 балл;<br>гигиена тәрбиясе бирү өлешендә медицина эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия булу – 15 балл |

3.3. Экспертиза үткәрү барышында экспертка билгеле булган мәгълүмат конфиденциаль булып тора һәм ул таратылырга тиеш түгел.

3.4. Конкурс комиссиясе проектлар рейтингын һәр критерий буенча экспертлар куйган баллар суммасы буенча формалаштыра, ул экспертлар тарафыннан куелган һәр критерий буенча баллар суммасыннан уртача арифметик юл белән исәпләп чыгарыла.

3.5. Экспертлар бәяләмәләрне керткәннән соң, вәкаләтле орган эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә гариза рейтингының минималь мәгънәсен (алга таба – гариза рейтингының минималь мәгънәсе) исәпләп чыгара, шуның белән бергә аны керткән конкурста катнашучы җиңүче дип танылырга мөмкин.

Гариза рейтингының минималь мәгънәсе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$М = \frac{ОКБ}{N},$$

монда:

М – гариза рейтингының минималь мәгънәсе;

ОКБ – конкурста катнашучылар җыйган балларның барлык суммасы;

N – конкурста катнашучылар саны.

Вәкаләтле орган гариза рейтингының минималь мәгънәсен исәпләп чыгарганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көндә номиналь коэффициент күләме турында карар кабул итү һәм гариза рейтингының иң чик мәгънәсен (алга таба – гариза рейтингының иң чик мәгънәсе) билгеләү өчен конкурс комиссиясе утырышын үткәрүне тәэмин итә, шуның белән бергә аны керткән конкурста катнашучы җиңүче дип таныла.

Гариза рейтингының иң чик мәгънәсе түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$Р = М \times К,$$

монда:

Р – гариза рейтингының иң чик мәгънәсе;

М – гариза рейтингының минималь мәгънәсе;

К – конкурс комиссиясе карары белән билгеләнә торган, 0,01 адымга артырып, 1 гә тигез булган номиналь коэффициент.

3.6. Гаризаларны карап тикшерү барышында конкурс комиссиясе үз утырышларына юридик затлар вәкилләрен чакырырга, аларга сораулар бирергә һәм алардан бу Тәртип белән билгеләнгән критерийлар буенча гаризаларны бәяләү өчен кирәкле мәгълүматны (шул исәптән документларны) соратып алырга.

3.7. Конкурс комиссиясе рейтингның иң чик мәгънәсен билгеләгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә конкурста җиңүчеләр исемлеген билгели.

Вәкаләтле орган конкурс комиссиясе тарафыннан конкурста җиңүчеләр исемлеге билгеләнгәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә боерык рәвешендә конкурста җиңүчеләргә субсидияләр бирү турында һәм бу Тәртипнең 4.1 нче пункты нигезендә билгеләнгән аларга бирү өчен субсидияләр күләме турында карар кабул итә.

3.8. Конкурс йомгаклары турында мәгълүмат (бирелә торган субсидияләр күләмнәрен күрсәтеп, конкурста җиңүчеләр исемлеге) субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә вәкаләтле орган тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштырыла.

## IV. Субсидия күләмен исәпләп чыгару тәртибе. Субсидия бирү һәм алардан файдалану шартлары

4.1. Конкурста җиңүчеләргә бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$C_i = \frac{S}{SUM} \times a_i,$$

$C_i$ – i конкурста җиңүчегә субсидия күләме;

S – субсидия күләме;

SUM – конкурста җиңүчеләр дип танылган барлык коммерциягә карамаган оешмалар җыйган баллар суммасы;

$a_i$ – экспертлар бәяләве буенча i конкурста җиңүче җыйган балларның барлык суммасы.

i конкурста җиңүче өчен бу пункт нигезендә билгеләнгән субсидия күләме i конкурста җиңүче сораган субсидия күләменнән артып киткән очракта, i конкурста җиңүченең субсидия күләме i конкурста җиңүче сораган субсидия күләменә тигез итеп билгеләнә, ә аерма бу пункт нигезендә конкурс буенча сайлап алу аша үткән конкурста җиңүчеләр арасында бүленә.

4.2. Вәкаләтле орган конкурста җиңүчеләргә субсидияләр бирү турында һәм аларга бирелә торган субсидияләр күләме турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә конкурста җиңүчеләр (алга таба – субсидия алучылар) белән Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә субсидияләр бирү турында килешүләр (алга таба – килешү) төзи.

Килешүдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, аны күчерү тәртибе һәм вакытлары карала, субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләре һәм субсидия алучының әлеге мәгънәләргә ирешүне тәэмин итү йөкләмәсе, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәлегеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү турында һәм субсидиядән файдалану турында хисап бирү вакытлары һәм формалары, хисап финанс елында файдаланылмаган субсидия акчасын кире кайтару очрагы, югары технологияле импорт җайланмаларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта турындагы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән башка, субсидия акчасы исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю, субсидия алучының вәкаләтле орган, дәүләт финанс тикшерүендә тоту органнары тарафыннан субсидия бирү шартларын, максатларын һәм аны бирү тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүне, шулай ук субидияләрне максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруга ризалыгы, килешү шартларын бозган өчен җаваплылык билгеләнә.

4.3. Субсидия алучы субсидия бирү нәтиҗәлелегенең килешүдә билгеләнгән түбәндәге күрсәткечләренә ирешүне тәэмин итәргә тиеш:

кереш (юнәлеш бирү) курсларында катнашкан мигрантлар саны;

кереш (юнәлеш бирү) курсларында катнашкан мигрантларның гомуми санында әлеге курсларда катнашканнан соң кереш (юнәлеш бирү) курслары

мәсьәләләре исемлеге буенча анкетаның тикшерү өчен барлык сорауларына дөрес җавап биргән мигрантлар өлеше.

4.4. Субсидия алучы белән төзелгән килешү нигезендә, вәкаләтле орган эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә акчаны субсидия алучының Россия кредит оешмасында ачылган хисап исәбенә субсидия алучы килешүдә күрсәтелгән максатлар өчен субсидиянең планлаштырыла торган сарыф итү чыгымнарын раслый торган документларны бирү шарты белән күчерә.

4.5. Субсидия алучы субсидия керү һәм аны сарыф итү буенча аерым бухгалтерлык исәбен алып бара.

4.6. Субсидия алучы субсидияне бирелгән гариза нигезендә максатчан билгеләнеш буенча файдаланырга тиеш. Субсидия алучы аларны тоту юнәлешләре арасында акчаны яңадан бүлү өлешендә бюджет проектына бирелә торган субсидиянең гомуми күләменнән 50 процент чикләрендә үзгәреш кертергә хокуклы. Үзгәрешләр кертү вәкаләтле орган белән килештерелә һәм субсидия бирү турындагы килешүгә өстәмә килешү төзелә.

4.7. Бирелгән субсидия исәбеннән субсидия алучы проектлар нигезендә түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашырырга хокуклы:

хезмәт өчен түләү буенча;

товарларга, эшләр башкаруга, хезмәт күрсәтүләргә түләү, аренда түләве буенча;

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәрен һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына башка мәҗбүри түләүләрне түләү буенча;

мөлкәти хокуклар, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокуклар сатып алу буенча;

командировкалар буенча;

ихтыярый затлар чыгымнарын каплау буенча;

проектны тормышка ашыру максатларына ирешүгә юнәлдерелгән чараларны оештыру һәм үткәрү буенча;

проектны тормышка ашыруны һәм аның нәтиҗәләрен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту буенча;

проектны тормышка ашыруга турыдан-туры бәйле булган башка чыгымнар буенча.

4.8. Бирелгән субсидияләр исәбеннән субсидия алучыга түбәндәге чыгымнарны гамәлгә ашыру рөхсәт ителми:

эшмәкәрлек эшчәнлеген гамәлгә ашыруга һәм коммерция оешмаларына ярдәм күрсәтүгә;

проектларны тормышка ашыруга турыдан-туры бәйле булмаган эшчәнлекне гамәлгә ашыруга;

сәяси партияләргә һәм сайлау кампанияләренә булышлык күрсәтүгә;

митинглар, демонстрацияләр, пикетлар үткәрүгә;

фундаменталь фәнни тикшеренүләргә;

алкогольле эчемлекләр һәм тәмәке продукциясе сатып алуга;

теләсә нинди штрафлар түләү буенча;

югары технологияле импорт җайланмаларын, чимал һәм комплектлау әйберләрен сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта турындагы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән башка, чит ил валютасы сатып алуга;

проектны тормышка ашыруга бәйле булмаган башка чыгымнарга.

V. Субсидияләрне кире кайтару тәртибе

5.1. Вәкаләтле орган субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә мәҗбүри тикшерү үткәрүне, шулай ук субсидияләрне максатчан файдалануны законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерүне гамәлгә ашыра.

5.2. Субсидия вәкаләтле органның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә субсидия алучы тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

түбәндәге очракта тулы күләмдә:

субсидия алу өчен дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырылган;

субсидия алучы тарафыннан вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган субсидия шартлары, максатлары һәм тәртибе бозылган;

килешү белән билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешү һәм субсидияне файдалану турында хисаплылык тапшырылмаган, хисаплылык тапшыру вакытлары бозылган;

субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең килешүдә билгеләнгән мәгънәләренә ирешелмәгән;

максатчан билгеләнештә файдаланылмаган субсидия күләмендә – субсидия акчасын максатчан файдаланмауны ачыклаган очракта.

Субсидия бирү турындагы килешү белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше проектны тормышка ашыру вакыты тәмамланган көннән 30 көн эчендә агымдагы финанс елында, әмма агымдагы финанс елының 1 декабреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә субсидия алучы тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

5.3. Бу Тәртипнең 5.2 нче пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытын субсидия алучы бозганда, вәкаләтле орган субсидияне кире кайтару вакытлары чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чара күрә.

___